**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru


---

2022елның 16 ноябре 2841номер

## КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш районының Олы Кабан поселогының«Аэросити»4 чират территориясен үзләштерү концепциясе» планлаштыру проектын раслау турында» 2022 елның 18 февралендәге 339 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында.**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 21 бүлегенең 45 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2013 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә, капиталь төзелеш объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен, линия объектларын төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, планлаштыру структурасы элементларын (кварталлар, микрорайоннар, башка элементлар) бүлеп бирү максатларында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Лаеш районының Олы Кабан поселогының«Аэросити»4 чират территориясен үзләштерү концепциясе» планлаштыру проектын раслау турында» 2022 елның 18 февралендәге 339 номерлы карарына ,территорияне планлаштыру проекты чикләрендә мәктәпкәчә һәм мәктәп белеем бирү объектларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләре булдыру максатыннан үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А. П. Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.А. Новиков**